**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**САТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

9 сентябрь 2021 ел №46

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июледәге 244-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Сатмыш авыл җирлеге Советы карар итте:

«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 179 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Каратун авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Сатмыш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 6 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына беркетелгән керем чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;»;

2) 5 статьяның 7 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«физик һәм юридик затларның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен акчалата чараларын, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрен «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;»;

3) 5 статьяның 8 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча, бюджетның бердәм счетындагы акчаларның калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш, керемнәр һәм түләүләр планлаштыра (фаразлый);»;

4) 5 статьяның 9 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча, бюджетның бердәм счетындагы акчаларның калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш, керемнәр һәм түләүләр планлаштыра (фаразлый);»;

5) 5 статьяның 9 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының бюджетка керүләренең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетындагы калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тота;»;

6) 17 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 маддәсендә каралган очракларда бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге;»;

7) 17 статьяның 2 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«әлеге Кодексның 160.2 статьясында каралган очракларда бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;».

2.Әлеге карарның 1 пунктындагы 3, 4, 5 пунктчалары 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Сатмыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

**Сатмыш авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р.Р. Сибгатова**